ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» июль 2022 ел № 163

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган “2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны тәңгәлләштерүгә бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты арасындагы “Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына башка бюджетара трансферлар бирү турында” Килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган “2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Программаның паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары: | Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме: | | |
|---|---|---|---|
| | ел | җирле бюджет | республика бюджеты |
| | 2021 | 200 мең сум | 122.5 мең сум (спорт җиһазлары); |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ел | | 331.4 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга) |
| | 2022 ел | 200 мең сум | 122.03 мең сум (спорт җиһазлары); 182.2 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга) |
| | 2022 ел | 28,7 мең сум | 2 872,4 мең сум (күнекмәләр футбол манежын оператив идарә итү хокукына беркетелү сәбәпле) |
| | Барлыгы | 428,7 мең сум | 3 630,53 мең сум |

1.2 «2021-2022 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү чаралары» 3 бүлегендәге «Матди-техник базаны үстерү» 5 бүлекчәсендәге 5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чаралар эчтәлеге | Башкару сроклары | Башкару өчен җаваплы затлар | Финанслау күләме (мең сум) | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 |
| 5.6 | Спорт мәктәпләрен җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча бюджетара трансфертлар (республика бюджеты) | 2021-2022 | МБУ «Спорт мәктәбе» | 122,50 | 122,03 |

1.3 «2021-2022 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чаралары» 3 бүлегенең «Матди-техник базаны үстерү» 5 бүлекчәсен 5.7 пункты белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

| № | Чаралар эчтәлеге | Башкару сроклары | Башкару өчен җаваплы затлар | Финанслау күләме (мең сум) | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5.7 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча күнекмәләр футбол манежы оператив идарә итү хокукына беркетелү сәбәпле хокукын нығытуга бәйле рәвештә бюджетара трансфертлар | 2022 | МБУ «Спорт мәктәбе» | | 2 872,4 |

2. Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 01 июнендәге 142 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**